РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» сентября 2026 ел г. Альметьевск № 1635

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы (Әлмәт шәһәре) үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Әлмәт муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2024 елның 14 августындагы 2664 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга һәм күрсәтелгән субсидияләрне алучыларны, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантларны сайлап алуны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы (Әлмәт шәһәре) үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Әлмәт муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2024 елның 14 августындагы 2664 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 22 июлендәге 1772 номерлы, 2025 елның 19 декабрендәге 2949 номерлы, 2026 елның 19 маендагы 842 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- тәртипкә 3 нче кушымтада:

комиссия составыннан И.Н. Шаргинаны чыгарырга;

комиссия составына Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты

заказ № 4553-940

Икътисад идарәсенең инвестицион үсеш һәм эшкуарлык бүлеге белгече К. Р. Спиридонованы кертергә;

комиссия әгъзасы А.Б. Насыйровның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад идарәсенең инвестицион үсеш һәм эшкуарлык бүлеге башлыгы.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов